| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
| --- | --- | --- |

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| --- | --- | --- |
| 26.12.2025 | г. Казань | № 716-64/т-2025 |

«Монолит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан керү тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә 2026 елга максималь чик тарифны билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.06.2023 ел, № 70-1/т-2023 карары белән расланган Татарстан Республикасында сәнәгать тимер юл транспорты оешмалары һәм башка хуҗалык субъектлары тарафыннан килә торган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә тарифлар билгеләү тәртибе, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 26.12.2025 ел, №36-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Монолит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан керү тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә әлеге карарга кушымта нигезендә максималь дәрәҗәдә чик тарифны билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф карар үз көченә кергән көннән алып 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
26.12.2025 № 716-64/т-2025
карарына кушымта

«Монолит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан керү тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә 2026 елга иң чик максималь тариф

| Т/с | Хезмәт төре | Чик дәрәҗә максималь тариф, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | «Химград» технополисы территориясендә 1 км ераклыкка 1 тонна йөк ташу | 38,20 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге